# КАРАР
# Татарстан Республикасының Азнакай район Советы

Азнакай шәһәре №303-41 «12» декабрь 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2015 елның 15 июнендәге 369-53 нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлаштыру нормативларын раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында
(13.12.2018 №221-32, 23.05.2019 №265-36, 20.08.2019 №283-38, 22.10.2019 №290-39 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексын үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 07.11.2019 елның 07 ноябрендәге 1417 нче номерлы «Торак биналардан файдалану кагыйдәләренә үзгәреш кертү турында» карары нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2015 елның 15 июнендәге 369-53 нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлаштыру нормативларын раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлаштыру нормативларына (13.12.2018 №221-32, 23.05.2019 №265-36, 20.08.2019 №283-38, 22.10.2019 №290-39 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.2 бүлектә 4.2.43 пунктының алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вөждан ирege һәм дини берләшмәләр турында» Федераль законның 16 статьясында каралган очраклардан тыш, торак урыннарында сәнәгать производстволары, кунакханәләр урнаштыру, шулай ук торак урыннарда

миссионерлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру рөхсәт ителми. Күп фатирлы йорттагы торак бина кунакханә хезмәте күрсәтү өчен кулланыла алмый.».

2 Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http: //aznakayevo. tatar. ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай район Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин